**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары (КАРАР)**

«09» ноябрь 2019 г.

№ 1

**Мамадыш муниципаль районы**
**Келәүш авыл җирлеге составына керүче**
**Сарбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш авылында 2019 елның 9 ноябрендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хэрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хэрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр,көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Сарбаш торак пунктындагы керү юлын вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

« ӘЙЕ»　　　　«ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 39 кеше кертелгән;

халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 28 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» 28 кеше тавыш бирде;

«Юк» 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Сарбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хэрби хәрәкәтләрдэ катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хэрби хәрәкәтләрдэ катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр,көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
-Сарбаш торак пунктындагы керү юлын вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге
Советы рәисе Б.В.Иванов